Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Кызылтау авыл җирлеге Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 4 мартындагы 5 номерлы карары

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Кызылтау авыл җирлегенең башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Кызылтау авыл җирлегенең башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2020 елның 10 августындагы 5 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1)адреслар бирү, үзгәртү һәм бетерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында (1-нче кушымта)

түбәндәге эчтәлекле 3.7.4 пункт өстәргә:

«3.7.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе Административ регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән гариза бирүчеләрнең гомуми билгеләре белән берләшкән категориясенә бәйле түгел. Шуңа бәйле рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтүнең гомуми билгеләре белән берләштерелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә күрсәтелгән хезмәт күрсәтү тәртибен үз эченә алган вариантлары, шул исәптән алар мөрәҗәгать иткән муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата да, билгеләнми.»;

2) нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында (2-нче кушымта)

түбәндәге эчтәлекле 3.6.4 пункт өстәргә:

«3.6.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе Административ регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән гариза бирүчеләрнең гомуми билгеләре белән берләшкән категориясенә бәйле түгел. Шуңа бәйле рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтүнең гомуми билгеләре белән берләштерелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә күрсәтелгән хезмәт күрсәтү тәртибен үз эченә алган вариантлары, шул исәптән алар мөрәҗәгать иткән муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата да, билгеләнми.».

3) агач һәм куакларны кисүгә, кронировкалауга яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында (4 нче кушымта)

түбәндәге эчтәлекле 3.8.4 пункт өстәргә:

«3.8.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе Административ регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән гариза бирүчеләрнең гомуми билгеләре белән берләшкән категориясенә бәйле түгел. Шуңа бәйле рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтүнең гомуми билгеләре белән берләштерелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә күрсәтелгән хезмәт күрсәтү тәртибен үз эченә алган вариантлары, шул исәптән алар мөрәҗәгать иткән муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата да, билгеләнми.».

4) карарның 1 пунктындагы дүртенче абзацын һәм муниципаль хезмәт күрсәтүнең белешмә (өземтә) бирү буенча административ регламентын (3 нче кушымтаны) үз көчен югалткан дип танырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында җирлек бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Кызылтау авыл
җирлеге башлыгы: М.Г.Нуриев